**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**КАРАР** — **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**28.10.2019** — **№1852**

# Архив документларының урнашу урыны мәсьәләләре буенча консультация бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, “Россия Федерациясендә архив эше турында”, 2004 елның 22 октябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына архив эше өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында”, 2007 елның 24 октябрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән Архив документларының урнашу урыны мәсьәләләре буенча консультация бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга.

2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының эшләре белән идарә итүче Сабирова Г.Ф.га йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе — Д.Ф.Шәйдуллин

Расланган
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты карары белән
28.10.2019 № 1852

# Архив документларының урнашу урыны мәсьәләләре буенча консультация бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент архив документларының урнашу урыны мәсьәләләре буенча консультация бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең (алга таба – муниципаль хезмәт) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Муниципаль хезмәтне алучылар: юридик затлар – муниципаль архивны туплау чыганаклары (алга таба – гариза бирүче)

1.3. Муниципаль хезмәт “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты” МКУ (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә.

Муниципаль хезмәтне башкаручы – Башкарма комитетның архив бүлеге (алга таба – Бүлек).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашкан урыны – Биектау тимер юл станциясе бистәсе, Кооперативная урамы, 5 йорт.

Бүлекнең урнашкан урыны: Биектау тимер юл станциясе бистәсе, Профсоюзная урамы, 1а йорты.

Башкарма комитетның эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, дүшәмбе-җомга 8.00 дән 17.00гә кадәр, төшке аш 12.00 дән 13.00 гә кадәр, чәршәмбе – кабул итү көне түгел.

Җәмәгать транспорты белән барып “Спорт комплексы” тукталышына кадәр:

- автобус № 91 номерлы автобус;

Казан – Арча юнәлешендәге шәһәр яны поезды белән “Биектау тимер юл станциясе бистәсе” тукталышына кадәр барасы.

Керү пропуск һәм (яки) шәхесне раслаучы документ буенча.

1.3.2. Бүлекнең белешмә өчен телефоны: (843) 65-74774.

1.3.3. Башкарма комитетның “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – “Интернет” челтәре) рәсми сайтында адресы: http://www. biektau@tatar.ru.

1.3.4. Муниципаль хезмәт, шулай ук Бүлекнең урнашкан урыны һәм эш графигы турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен, Башкарма комитет биналарында урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүмат туплаган муниципаль хезмәт турында мәгълүмат стендлары аша;

2) «Интернет» челтәре аша:

Башкарма комитетның рәсми сайтында (http://www. biektau@tatar.ru);

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi. tatar.ru/);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләр) бердәм порталында (http://

www.gosuslugi.ru/);

3) Бүлеккә телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә – кәгазьдә почта аша, электрон формада электрон почта аша;

5) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба – КФҮ), КФҮнең еракта урнашкан эш урыннарында.

1.3.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан Башкарма комитетның рәсми сайтында һәм гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Башкарма комитет биналарында мәгълүмати стендларда урнаштырыла.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләргә туры китереп гамәлгә ашырыла:

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 131-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар Җыелмасы, 2003, №40, ст.3822, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Россия Федерациясендә Архив эше турында”, 2004 елның 22 октябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 125-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары Җыелмасы, 2004, № 43, 4169 ст. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары Җыелмасы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Федераль башкарма хакимият органнарында эшләр алып бару кагыйдәләрен раслау турында”, 2009 елның 15 июнендәге 477 номерлы карары, (алга таба – Эшләр алып бару кагыйдәләре) (Российская газета, 24.06.2009 № 4937, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының 2015 елның 31 мартындагы 526 номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм муниципаль һәм муниципаль архивларда, музейларда һәм китапханәләрдә, Россия Фәннәр академиясе оешмаларында саклауны, комплектлаштыруны, исәпкә алуны һәм алардан файдалануны оештыру кагыйдәләре (алга таба - Кагыйдәләр);

“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 45-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, 03.08.2004, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасында архив эше турында”, 2017 елның 20 июлендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 63-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Татарстан Республикасы законнары Җыелмасы, 25.07.2007, Т 55 ( I бүлек), ст. 2016));

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр төзелгәнче, берләшкәнче, бүленгәнче яисә аларның статусы үзгәргәнче барлыкка килгән һәм Татарстан Республикасы

муниципаль архивларында саклана торган архив документларын исәпкә алуны тәэмин итү турында”, 2007 елның, 28 маендагы 203 номерлы карары (алга таба – ТР МК 203 номерлы карары) (Республика Татарстан, 2007, 25 декабрь, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Биектау муниципаль районы Советының 2014 елның 21 сентябрендәге 7 номерлы карары белән расланган, Биектау муниципаль районы Советының 28.09.2016 № 86, 29.11.2016 № 110, 26.09.2017 № 145, 28.03.2018 N 205 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставы (алга таба – Устав);

Биектау муниципаль районы Советының 2017 елның 16 февралендәге 122 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты” МКУ турында нигезләмә (алга таба – Башкарма комитет турында Нигезләмә);

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан 2006 елның 11 гыйнварында расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге турында Нигезләмә (алга таба – бүлек турында Нигезләмә);

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетның 2010 елның 30 декабрендәге 3038 номерлы карары белән расланган Эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең еракта урнашкан эш урыны – муниципаль районның авыл җирлекләрендә гариза бирүчеләрнең документларын кабул итү һәм бирү, консультацияләр бирү тәрәзәсе;

техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документларга кертелгән мәгълүматлар (муниципаль хезмәт нәтиҗәсе) документтагы мәгълүмат нигезендә кертелгән мәгълүматларга туры килмәүгә китергән хата (ялгыш язу, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яки шуның ише хата).

муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза астында (алга таба – гариза) муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату аңлашыла (27.07.2010, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 1 пукнты 2 ст.). Гариза ирекле формада, билгеләнгән үрнәк буенча яки стандарт бланкта тутырыла (1 нче кушымта);

Гариза стандарт бланката электрон формада тутырыла:

Башкарма комитетның рәсми сайтында (http://www.vusokaua-gora.tatar.ru);

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi. tatar.ru/);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләр) бердәм порталында (http:// www.gosuslugi.ru/).

## 2. **Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты**

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр исеме | Стандарт таләпләренең эчтәлеге | Муниципаль хезмәте күрсәтү яисә таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү исеме | Архив документларының урнашу урыны мәсьәләләре буенча консультация бирү | 125-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарәнең башкарма-оештыручы органы исеме | “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты” МКУ.<br>Муниципаль хезмәтне башкаручы – Башкарма комитетның Архив бүлеге | 125-ФЗ номерлы Федераль законның 4 ст. 3,5 бүлекләре;<br>Бүлек турында Нигезләмә |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләренең тасвирламасы | Соратыла торган мәгълүматларның булуы һәм урнашу урыны буенча консультацияләр бирү | 125-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы | Гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне. (1) | 02.05.2006, 59-ФЗ номерлы Федераль законның 12 ст.;<br>Эш Кагыйдәләренең 5.8.3 п. |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр | Мөрәҗәгать (шәхсән кабул иткәндә яки телефон буенча, Биектау муниципаль районы рәсми сайты аркылы электрон документ формасында, факсимиль хат белән мөрәҗәгать).<br>Шәхсән кабул иткәндә гражданин шәхесен раслаучы документны тәкъдим итә. | 210-ФЗ номерлы Федераль законның 19 ст. 1 бүлеге;<br>Эш Кагыйдәләренең 5.8, 5.10 п |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм мөрәҗәгать итүче тәкъдим итәргә хокуклы башка оешмалар карамагында булган | Әлеге категориягә кертелергә мөмкин булган документларны тәкъдим итү таләп ителми. | |

| | | |
|---|---|---|
| муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, шулай ук аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | | |
| 2.7. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган, аларны килештерү очраклары норматив хокукый актлар белән каралган дәүләт хакимияте (җирле үзидарә органнары) органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Муниципаль хезмәтне килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Документларны кабул итүдән баш тарту каралмаган | |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки бирүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Баш тарту өчен нигезләр:<br>1. Мөрәҗәгатьнең нигезе буенча моңа кадәр җавап бирелгән булса. | |

| | | |
|---|---|---|
| | 2. Документларның урнашкан урыны турында мәгълүматлар булмавы | |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтүләр өчен алына торган дәүләт пошлинасы яисә башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, әлеге түләүнең исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә | 125-ФЗ номерлы Федераль законның 15 ст. 3 пункты, 26 ст. 4 пункты;<br>210-ФЗ номерлы Федераль законның 8 ст. 1 бүлеге |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату биргәндә һәм мондый хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты | Муниципаль хезмәтне алучының (гариза бирүченең) сорату биргәндә һәм нәтиҗә алганда кабул итүне көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Аерым категория муниципаль хезмәт алучылар өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турында соратуын, шул исәптән электрон формада да теркәү вакыты | Гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада кергән сорату ял (бәйрәм) көне артыннан килгән эш көнендә теркәлә | 59-ФЗ номерлы Федераль законның 8 ст. 2 бүлеге;<br>16-ТРЗ номерлы ТР Законының 7, 17 ст.;<br>Делопроизводство Кагыйдәләренең IV бүлеге 16 п. |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән, | |

| | | |
|---|---|---|
| көтү һәм кабул итү урынына, шул исәптән, инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, әлеге объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итүгә, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә таләпләр | документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар белән җиһазландырылган биналарда башкарыла.<br>Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин ителә (бинага уңайлы керү-чыгу һәм аларның чикләрендә хәрәкәт итү).<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла | |
| 2.15. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән үзара хезмәттәшлеге күләме һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә муниципаль хезмәт алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең ераклаштырылган эш урыннарында, муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати- | Муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:<br>Бүлек бинасының җәмәгать транспортының һәркем файдалана алырлык зонасында урнашкан булуы;<br>кирәкле сандагы белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналар булу;<br>мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендәге http://www.vusokaua-gora.tatar.ru мәгълүмати ресурсларында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу; | 125-ФЗ номерлы Федераль законның 24 ст. 1 бүлеге |

| | | |
|---|---|---|
| коммуникацион технологияләр кулланып | Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (фукнцияләр) бердәм порталында;<br>башка затлар белән берләттән хезмәт күрсәтүе алучы инвалидларга комачаулаучы киртәләрне җиңеп чыгарга ярдәм күрсәтү.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>гариза бирүчеләрдән документлар кабул иткәндә һәм биргәндә чиратлар;<br>муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозу;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе алганда – муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затның һәм мөрәҗәгать итүченең бер тапкыр үзара хезмәттәшлеге. Хезмәттәшлекнең дәвамлылыгы әлеге Регламент белән билгеләнә.<br>Күпфункцияле үзәктә (алга таба – КФҮ) муниципаль хезмәт күрсәткәндә, КФҮнең еракта урнашкан эш урыннарында консультация бирүне, документлар кабул итүне һәм бирүне КФҮ белгече башкара. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан Башкарма комитет сайтында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (фукнцияләр) бердәм порталында, КФҮдә, КФҮнең еракта урнашкан эш урыннарында алынырга мөмкин | |
| 2.16. Муниципаль хезмәтне электрон формада тәкъдим итү үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза электрон документ формасында түбәндәге электрон адрес буенча җибәрелергә мөмкин:<br>E-mal: biektau@tatar.ru | 210-ФЗ номерлы Федераль законның 19 ст. 1 бүлеге;<br>16-ТРЗ номерлы ТР Законының 5 ст. |
| 2.17. Муниципаль хезмәтне күпфункцияле үзәкләрдә тәкъдим итү үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәтне күпфункцияле үзәкләрдә (алга таба – КФҮ) күрсәткәндә, консультация, документларны кабул итү һәм бирүне КФҮ хезмәткәре тормышка ашыра. | 210-ФЗ номерлы Федераль законның 14 ст. |

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә, күпфункцияле үзәгенең ераклаштырылган эш урыннарында административ процедураларны башкару үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләр тәртибе тасвирламасы

3.1.1. Архив документларының урнашкан урыны буенча консультацияләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультацияләр бирү, гариза төзегәндә/тутырганда ярдәм күрсәтү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) архив документларының урнашкан урыны мәсьәләләре буенча мәгълүмат җыю;

4) гариза бирүчегә муниципаль хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы 2 нче кушымтада китерелгән.

3.2. Гариза бирүчегә консультацияләр бирү, гариза төзегәндә/тутырганда ярдәм күрсәтү.

Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында консультацияләр алу өчен Бүлеккә шәхсән үзе, телефон аша һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итә.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә консультация бирә, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле документлар составы, формасы һәм башка сораулар буенча һәм кирәк булганда гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә консультация бирү.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән үзе (ышанычлы зат аша) яки КФҮ аша, муниципаль хезмәт күрсәтү турында кәгазьдә язма рәвештә, электрон почта ярдәмендә Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (фукнцияләр) бердәм порталы, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Башкарма комитетның рәсми сайты яисә почта аша гариза бирә (җибәрә). Документлар КФҮ еракта урнашкан эш урыны аркылы бирелергә мөмкин. Еракта урнашкан эш урыннары исемлеге 23 биттәге кушымтада китерелгән.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гариза электрон формада Бүлеккә электрон почта, Башкарма комитетның Интернет-кабул итү бүлмәсе аша җибәрелә. Электрон формада килгән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

3.3.2. Бүлек белгече гаризаны терки.

Әлеге пункт белән билгеләнән торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткәннән соң 15 минут дәвамында тормышка ашырыла.

Процедурларның нәтиҗәсе: теркәлгән гариза.

3.4. Архив документларының урнашкан урыны мәсьәләләре буенча мәгълүмат җыю

3.4.1. Бүлек белгече:

архивта документлар булуын тикшерә;

архивта кирәкле документлар булмаган очракта, документларны белешмәләрнең мөмкин булган базалары буенча эзли;

гариза бирүчедән өстәмә мәгълүматны алу кирәк булган очракта, гариза бирүчегә сорату ясый;

документларның урнашкан җирен билгеләгәннән соң язмача формада (факс буенча), электрон хәбәрләр рәвешендә, шәхсән кабул итү вакытында гариза бирүчегә телдән хәбәр итү рәвешендә яисә телефоннан документның урнашкан җире турында кирәкле белешмәләрне хәбәр итә;

архивта документ булган очракта, гариза бирүчегә архив белешмәсен (архив өземтәсен, архив документлары күчермәләрен) бирү турында гариза (язмача яисә электрон документ рәвешендә) тутырырыга тәкъдим итә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә документларның урнашкан җире буенча консультация бирү.

3.5. Муниципаль хезмәтне КФҮ аша күрсәтү.

3.5.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтелү турында КФҮкә, КФҮнең еракта урнашкан эш урынына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.5.2. КФҮ аша гаризаларны кабул итү билгеләнгән тәртиптә расланган КФҮ эше регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.5.3. КФҮдән муниципаль хезмәт күрсәтүгә гаризалар кергәндә, процедуралар әлеге бердәй административ әлеге Регламентның 3.3, 3.4 пунктлаы нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.6. Техник хаталарны төзәтү

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак, гариза бирүчегә Башкарма комитет тарафыннан документ бирелмәгәнлектә, техник хаталарны төзәтү гамәлгә ашырылмый.

## 4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту үз эченә ала: гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының шикаятьләрен карау, үтәлешен тикшерү, җирле үзидарә органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләү кирә.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып тора:

муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документлар проектларын хокукый тикшерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;

билгеләнгән тәртиптә башкарыла торган эшләр башкаруын тикшерү;

муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешенә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерү үткәрү.

Контроль тикшерүләр план нигезендә (җирле үзидарә органы эшчәнлегенең ярты еллык яки еллык планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда муниципаль хезмәт күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле барлык мәсьәләләр дә карала ала. Гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча планнан тыш тикшерүләр уздырыла.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләр үтәлешенә агымдагы контроль Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты эшләре белән идарә итүче тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге җирле үзидарә органының структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи регламентлар турында нигезләмәләр белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Бүлек начальнигы әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ процедураларны вакытында һәм (яки) тиешенчә карап тикшермәгәне өчен җаваплылык тота.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту, Башкарма комитет эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү вакытында муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөреслеккә туры килә торган мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аркылы тормышка ашырыла.

## 5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, яисә муниципаль хезмәткәрләрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, шулай ук 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 бүлеге белән күздә тотылган оешмаларның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) гариза бирүченең судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү предметы

5.1. Муниципаль хезмәтне алучылар муниципаль хезмәт тәкъдим итүдә катнашучы Башкарма комитет хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр шикаять белән Башкарма комитетка, Башкарма комитет җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) муниципаль берәмлек Советына шикаять белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять закон белән билгеләнгән тәртиптә шикаять ителә.

5.2. Гариза бирүче шикаять белән шул исәптән түбәндәге очракларда да мөрәҗәгать итә ала:

1) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында күрсәтелгән муниципаль хезмәтне күрсәтү турында соратуның теркәү срогын бозу.

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу. Күрсәтелгән очракта, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) гариза бирүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә билгеле дәүләт яки муниципаль хезмәтне тулы итеп, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 нчы статьясы 1.3 бүлеге белән билгеләнгән тәртиптә күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта гына мөмкин.

3) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерацисе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларында каралмаган өстәмә документлар яки мәгълүмат яисә эшчәнлек таләп итү;

4) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда күздә тотылган документларны кабул итүне кире кагу;

5) федераль законнар, федераль законнар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка төр норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка төр норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актларында кире кагу өчен җирлек булмаган очракта муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту. Күрсәтелгән очракта, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) гариза бирүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә билгеле дәүләт яки муниципаль хезмәтне тулы итеп 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 нчы статьясы 1.3 бүлеге белән билгеләнгән тәртиптә күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта гына мөмкин.

6) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәткән очракта Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъекты норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 бүлегендә күздә тотылган оешмаларның, яки аларның хезмәткәрләренең дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә документларда алар җибәргән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тарту, яисә андый төзәтмәләрнең билгеләнгән срогын бозган очракта. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелгән күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү тулы күләмдә һәм тәртиптә булган очракта гына мөмкин;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буенча документлар бирүнең срогын һәм тәртибен бозу;

9) муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору, әгәр дә федераль законнар, алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка төр норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектлары законнары һәм башка төр норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актларында монының өчен нигез булмаса. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелгән күпфункцияле 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү тулы күләмдә һәм тәртиптә булган очракта гына мөмкин;

10) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән беренче тапкыр муниципаль хезмәт күрсәткән вакытта кирәкле булган документларны кире какканда аларның юклыгы һәм (яки) тулы булмаганлыгы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматларны таләп итү, яисә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы 1 бүлеге 4 пунктында каралган очраклардан кала. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелгән күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү тулы күләмдә һәм тәртиптә булган очракта гына мөмкин.

5.3. Муниципаль хезмәтне алучы шикаятьне нигезләү һәм карау өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматларны алырга хокуклы.

5.4. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон формада җибәрелә.

Шикаять почта, күпфункцияле үзәк, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәре, Биектау муниципаль районы рәсми сайты (http://vysokaya-gora.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. Күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү почта, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәре, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайты, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (функцияләр), шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы “г” бүлегендә каралган оешмалар һәм шулай ук аларның хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү почта, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәре, әлеге оешмаларның рәсми сайтлары, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (функцияләр), шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.5. Шикаятьне карау срогы – аны теркәгән көннән башлап, унбиш эш көне дәвамында. Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының кире кагуын шикаять иткән очракта, күпфункцияле

үзәк, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 бүлегендә каралган оешмалар гариза бирүчедән документларны кабул итүдән баш тарткан яисә җибәрелгән ялгышларны һәм хәреф-хаталарын төзәтүдә яки әлеге төзәтмәләрнең билгеләнгән срогын бозган вакытта - аны теркәгән көннән башлап, биш эш көне дәвамында.

5.6. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелүче муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, муниципаль хезмәт күрсәтү органы вазыйфаи затының, яисә дәүләт яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесе һәм (яки) хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 бүлегендә каралган оешмалар, аларның җитәкчеләренең һәм (яки) аларның хезмәткәрләренең исемнәре;

2) гариза бирүчегә җавап бирү өчен фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы булган очракта), гариза бирүченең яшәү урыны турында белешмә – физик затның яисә исеме, гариза бирүче юридик затның урнашкан урыны турында белешмә, хәбәрләшү өчен телефон номеры, электрон почта адресы (адреслары) (ахыргысы булган очракта) һәм почта адресы;

3) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелүче муниципаль хезмәт күрсәтү органы, муниципаль хезмәт күрсәтү органы вазыйфаи заты, яисә дәүләт яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 бүлегендә каралган оешмалар, аларның хезмәткәрләре турында мәгълүматлар;

4) муниципаль хезмәте күрсәтү органы, муниципаль хезмәте күрсәтү органы вазыйфаи заты, яисә дәүләт яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 бүлегендә каралган оешмалар, аларның хезмәткәрләренең карарлары һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) дәлилләре белән гариза бирүче килешмәү нигезендә.

5.7. Гариза бирүче тарафыннан гариза бирүченең дәлилләрен раслаучы документлар, яисә аларның күчермәләрен тәкъдим ителә ала (булган очракта).

5.8. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча, түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны кире кагу формасында, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән гаризаны кертү вакытында җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтү буенча төзәтмәләрне, гариза бирүчегә акчалата чараларны кире кайтару, ләкин акча алу Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар нигезендә каралмаган;

2) шикаять канәгатьләндерелүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгәннең икенче көннән үк соңга калмыйча, гариза бирүчегә язма рәвештә, теләге булган очракта электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре күрсәтелгән дәлилләнгән җавап хаты җибәрелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта гариза бирүчегә җибәрелә торган җавапта дәүләт хезмәте күрсәтү вакытында ачыкланган кагыйдә бозулар

кичекмәстән юкка чыгару өчен муниципаль хезмәт күрсәтү органының, күпфункцияле үзәкнең, яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 бүлегендә каралган оешмаларның эшчәнлекләре турында мәгълүмат бирелә, шулай ук гариза бирүчедән китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу сорала һәм киләчәктә муниципаль хезмәт алу максатларында гариза бирүче эшләргә тиешле эшчәнлек турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.10. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, кабул ителгән карарның сәбәпләрен аңлатып нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарны шикаять итү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.11. Карарны кабул итү барышында яки шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки вазыйфаи зат тарафыннан хокук бозу очраклары булу мөмкинлеге ачыкланса, шикаятьятләрне карау буенча вәкаләтләргә ия булган хезмәткәр барлык материалларны прокуратура органнарына җибәрелә.

1 нче кушымта
Архив документларының урнашу урыны мәсьәләләре буенча консультация бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына

______________________________________________
(муниципаль берәмлекнең җирле
______________________________________________
үзидарә органына)
________________________________________нан
(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспорт белешмәләре, почта индексы, адресы, телефоны)

Архив документларының урнашкан урыны мәсьәләләре буенча консультацияләр бирү турында
ГАРИЗА

Документларның (тарих буенча документларның) урнашкан җире турында белешмәләрне хәбәр итүегезне үтенәм ____________________________________________________________,
(оешманың, бүлекнең, цехның, бригаданың; торак пунктының атамасы)

адресы буенча урнашкан:____________________________________________
еллар өчен ____________________________________________________. Документлар архив белешмәсен (күчермәсен, өземтәсен) алу өчен кирәкле
стаж турында ____________________________________________________________
(учреждение атамасы)

еллар өчен ____________________________________________________________
хезмәт хакы турында ____________________________________________________
(учреждение атамасы)

еллар өчен ____________________________________________________________
уку туырнда ____________________________________________________________
(учреждение атамасы)


еллар өчен ____________________________________________________________

башкасы__________________________________________________________________
еллар өчен ______________________________________________________________

Дата ______________________ ________________________
(Имза)

2 нче кушымта
Архив документларының урнашу урыны мәсьәләләре буенча консультация бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына

## Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге блок-схемасы



3 нче кушымта
Архив документларының урнашу урыны мәсьәләләре буенча консультация бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына

Еракта урнашкан эш урыннары исемлеге һәм документларны кабул итү графигы

| № т/б | Ерактагы эш урынының урнашкан урыны | Хезмәт күрсәтелә торган торак пунктлар | Документларны кабул итү графигы |
|---|---|---|---|
| 1 | Биектау авылы, Полковая урамы, 9 йорт | Биектау районы | Дүш-Җом - 8:00-17:00<br>Шим – 8:00-13:00<br><br>Сиш –14:00-17:00 (консультация) |

4 нче кушымта
Архив документларының урнашу урыны мәсьәләләре буенча консультация бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына

“Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты” МКУ
Җитәкчесенә
________________________нан

**Техник хатаны төзәтү турында**
**гариза**

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм _________________________________________________________________

(хезмәт күрсәтү исеме)

Язылган:_________________________________________________________________

_________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар:_________________________________________________________________

_________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

3.

Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, мондый карарны җибәрүегезне сорыйм:

электрон документны җибәрү адресы E-mail:________________________;

расланган күчермә рәвешендә кәгазьдә почта аша түбәндәге адрес буенча: ____________________________________________________________________.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыю, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), шәхси үзенчәлекләрне бетерү, блокадалау, шәхси мәгълүматларны юк итү, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле бүтән гамәлләр кабул итүне дә кертеп) үз ризалыгымны, мин тәкъдим итә торган затның ризалыгын раслыйм, шул исәптән автоматлаштыру режимында, муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан карарлар кабул итүне дә кертеп.

Раслыйм: гаризага кертелгән минем шәхесемә һәм мин тәкъдим иткән затка кагылышлы, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага кушып бирелгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза биргән вакытта бу документлар гамәлдә һәм анда дөрес мәгълүматлар кертелгән.

Телефон аша бирелгән муниципаль хезмәтләрнең сыйфатын бәяләү буенча сораштыруда катнашырга үземнең ризалыгымны бирәм: ________________________.

_______________ __________________ ( _________________)

(дата) (имза) (Ф.И.О.)

Мәгълүмат өчен
(белешмә)

Архив белешмәләрен, архив өземтәләрен, архив документлары күчермәләрен бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аны күрсәтүне тикшереп торучы вазыйфаи затларның реквизитлары

“Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУнең архив бүлеге

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Бүлек начальнигы | 8-84365-74774 | Faniya.Askarova@tatar.ru |
| Бүлек белгече | 8-84365-74774 | |

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ җитәкчесе | 8-84365-23061 | Damir.Shaydullin@tatar.ru |
| “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ эшләре белән идарә итүче | 8-84365-23063 | Sabirova.Guzel@tatar.ru |